Галим, З. Рәшит Бәшәргә - 75 / З. Галим // Шәри Чаллы. – 2024. – №93 (25 декабрь). – Б. 5.





/ ФОТО ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ЧАЛЛЫ БҮЛЕГЕ СОЦ ЧЕЛТӘРЕННӘН

# Рәшит Бәшәргә –75

Зөлфия **Галим**

**Чаллыда Абдулла Алиш, Шәүкәт Галиев исемендәге әдәби премияләр лауреаты, язучы Рәшит Бәшәрнең 75 яшьлек юбилеена багышланган тантаналы чара узды.**

Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов язучының тормышына һәм иҗатына багышланган театраль тамаша әзерләде.

Юбилярны ТР язучылар берлеге рәисе Ракил Зәйдуллин, шәһәр Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Винер Харисов, язучылар, мәдәният һәм сәнгать әһелләре котлады.

Язучыларның әсәрләре җыр, биюләр белән үрелеп барды. 2, 29, 54, 59нчы гимназия, 84нче Г.Акыш исемендәге лицей-интернат укучылары Рәшит Бәшәрнең әсәрләрен укыдылар, артистлык сәләтләрен дә күрсәттеләр. «Агадир» цирк студиясе чыгышы да нур өстенә нур булды.